ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2024 Балык Бистәсе штп. № 53пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында ГТО комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үзәкләрен булдыру турында" 22.12.2015 №365пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Оештыру-штат чаралары, аерым кешеләрнең башка эшкә күчүләре һәм "Спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе исемен үзгәртү белән бәйле рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында ГТО комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үзәкләрен булдыру турында" 22.12.2015 №365пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балалар–яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба-«ДЮСШ» ӨБ МБУ)» сүзен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «СМ» ӨБ МБУ)» сүзләре белән алыштырырга.

1.2. 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җитәкчеләр итеп билгеләргә:

3.1.1. «СОК "Дельфин" МБУнең тест үткәрү үзәгенә - "СОК Дельфин" МБУ директоры Җамалиев Рәсим Бәдертдин улын;

3.1.2. «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе тест үткәрү үзәгенә- «СМ» ӨБ МБУ директоры Хәбибуллин Ленар Рафаэль улын.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” нда һәм Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ начальнигы И.З. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов